Шәйх Хәйсәм ибн
Мөхәммәд Сәрхән

# Яшерен булган нәрсәләрдән ачкыч

مفاتيح الغيب

اللغة التتارية

ALSARHAAN.COM
Mahadsunnah.com

Аллаһка гына хас булган гыйлем – ул яшерен нәрсәләрдән хәбәрдар булу. Үткәнне дә, хәзергене дә, булачак хәлләрне дә Аллаһтан башка беркем дә белми.

Аллаһ Раббыбыз әйтте: «Әйт, Аллаһтан кала җирдә дә күктә дә яшерен нәрсәләрне беркем дә белми. Алар хәттә кайчан терелтеләчәкләрен дә сизмиләр». (Ән-Нәмл сүрәсе, 65 аят)

Ләкин Аллаһ, Үзенең пәйгамбәренә аңа кадәр булган кайбер пәйгамбәрләрнең тарихларын ачкан шикелле , кайсыдыр колларына да яшерен булган нәрсәләрен ача. Шулай ук Аллаһ пәйгамбәребезгә ﷺ Кыямәт көненең галәмәтләрен һәм киләчәктә булачак башка яшерен булган бөек нәрсәләрне ачты.

Аллаһ әйтте: «Ул яшерен нәрсәләрне белүчедер, һәм Ул үзенең яшерен эшләренә Үзе риза булып, аларны пәйгамбәр иткән мәхлүкларыннан кала һичкемне хәбәрдар кылмас. Һәм аларга тапшырылган йомышларын ирештергәннәрен белсен өчен аларның алларына һәм артларына сакчы фәрештәләрен билгеләгән. Алар турында һәрнәрсәне Аллаһ белүче һәм Ул һәрнәрсәнең санын беләдер». (Әл-җин сүрәсе, 26-28 аятләр)

Раббыбыз биш төп яшерен нәрсәләрне барлык мәхлуклардан да яшереп тота.

Шуңа күрә Аллаһтан башка беркем дә Кыямәт көне кайчан булачагын, яңгырның кайда һәм кайсы вакытта явачагын, ана карынында тулысынча, тәфсилле итеп кем барын беркем дә белми. Аллаһ аналыкта булган җан ияләрен үстерүче. Һәм шул җанның малаймы, кызмы икәнен, ризыгын, гомере озынлыгын һәм аның гамәлләрен, бәхетле ме бәхетсезме булачагын белүче.

Шулай ук иртәгәсе көнне җан иясенең яхшылыккамы яки начарлыккамы дучар булуын, ризыгының аз мы күп ме булуын Аллаһтан башка беркем дә белми.

Шулай ук җан ияләренең кайсы җирдә ничек үләсен Аллаһтан башка беркем дә белми.

Табиплар яки метеорологлар әйткән: Балага узу, җил чыгу, яңгыр яву, кояш, я ай тотылу кебек әлегә килеп чыкмаган яки булачак нәрсәләр барысы да чама белән исәпләнә һәм ныклы фикергә нигезләнми. Әлбәттә бу исәпләүләр дөрес тә хаталы да булырга мөмкин.

Ләкин шул һәм башка нәрсәләр турында Аллаһның гыйлеме ышанычлы, тулы, төгәл һәм монда хата да, шикләнү дә булырга һич мөмкин түгел.

Аллаһ әйтте: «Әлбәттә, Кыяматнең кайчан булачагын белү Аллаһ хозурындадыр, яңгыр явуын, һәм хатын-кызларның карыннарында кем барлыгын белүче Ул. Һәм һичбер кеше кайда үләчәген һәм иртәгә нәрсә эшләячәген белмәс, Аллаһ һәрнәрсәне белүче һәм һәрнәрсәдән хәбәрдардыр». (Локман сүрәсе 34 аять)